| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022елның 30 ноябре Борындык ав. № 42

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 17 ноябрендәге 34 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1.3 пунктчасын өстәргә:

«2.1.3 «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзалары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә җитмәгән яисә бу яшьтән өлкәнрәк балалары, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булган булсалар, шулай ук көндезге бүлектә белем алучылар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәннән дә соңга калмыйча.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң көченә керә.

3. Әлеге карарының 1 пунктындагы 1.2.2 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге Башлыгы А.Р.Гайнетдинов